КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 декабрь г.Казань № 1093

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 774 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 923 нче; 2020 ел, 14 апрель, 285 нче; 2020 ел, 30 июнь, 548 нче; 2020 ел, 16 июль, 600 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 779 нчы; 2021 ел, 15 февраль, 82 нче; 2021 ел, 5 май, 309 нчы; 2021 ел, 8 июнь, 442 нче; 2021 ел, 16 август, 731 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 22 ноябрь, 1109 нчы; 2022 ел, 3 февраль, 81 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1047 нче; 2022 ел, 31 октябрь, 1159 нчы; 2022 ел, 20 декабрь, 1375 нче; 2023 ел, 24 февраль, 182 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче; 2023 ел, 19 октябрь, 1323 нче; 2023 ел, 11 декабрь, 1599 нчы; 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче; 2024 ел, 31 гыйнвар, 50 нче; 2024 ел, 13 февраль, 76 нчы; 2024 ел, 25 май, 365 нче; 2024 ел, 2 август, 614 нче; 2024 ел, 28 сентябрь, 840 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә, 5.4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Үз-үзенә хезмәт күрсәтүгә, мөстәкыйль хәрәкәтләнүгә, үзенең торган урынын билгеләүгә һәм үз тотышын контрольдә тотуга сәләте III дәрәҗәдә чикләнгән I төркем инвалидлар (2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә, шулай ук 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм итүче оешмалар белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләренә ия булган), әлеге бурычларны үтәүгә ярдәм итү йөкләмәләрен башкаруга бәйле рәвештә алынган яралану, контузия, гарипләнү яки авыру аркасында инвалид булган, чит кеше каравына даими мохтаҗ булган, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Идел» инвалидларны социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә 90 эш көне дәвамында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтелә торган затлардан тыш) 18 яше тулган һәм инвалидларны карауны гамәлгә ашырырга сәләтле (ул мәҗбүри булып тора), даими ярдәм итеп торучы зат белән инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренә кабул ителә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче; 2020 ел, 6 июль, 555 нче; 2021 ел, 21 апрель, 268 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2022 ел, 12 декабрь, 1316 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1493 нче; 2023 ел, 1 март, 195 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 13 июль, 823 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 23 август, 1003 нче; 2023 ел, 31 август, 1054 нче; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче; 2023 ел, 10 октябрь, 1293 нче; 2023 ел, 11 декабрь, 1599 нчы; 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче; 2024 ел, 13 февраль, 76 нчы; 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче; 2024 ел, 25 май, 365 нче; 2024 ел, 8 июль, 537 нче; 2024 ел, 2 август, 614 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә, 3.4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Үз-үзенә хезмәт күрсәтүгә, мөстәкыйль хәрәкәтләнүгә, үзенең торган урынын билгеләүгә һәм үз тотышын контрольдә тотуга сәләте III дәрәҗәдә чикләнгән I төркем инвалидлар 18 яше тулган һәм инвалидларны карауны гамәлгә ашырырга сәләтле (ул мәҗбүри булып тора), даими ярдәм итеп торучы зат белән инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренә кабул ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин